Тарих

# «Булгарская цивилизация на Волге» китабы татар кешесендә горурлык уята, башка милләт вәкиленең күзен ача



Һәйкәл ачу тантанасы

460 ел элек татар үзенең дәүләтчелегеннән колак каккач, милләт буларак, сүнү сукмагына басты.

Ислам диненнән ваз кичтерү, көчләп чукындыру, мыскыллау, телдән биздерү, асыл гореф-гадәтләребездән арындыру, хәләлнең нәрсә икәнен онытыру, интернационализм байрагына чорнап урыслаштыру сәясәтен сеңдерү - барчасы да татарны юк итү максатыннан эшләнде.

Хәзерге вакытта уйлап чыгарылган толерантность шулпасы да - татарның башын бөгү, авызын ачтырмау сәясәтенең бер төре.

Максат бер иде - татарны милләт буларак юк итү. Биш гасыр дәвамында югалтуларга дучар булган мөселман татарына бүген соклану гына кала. Халык әхлагын эзгә салуда гаҗәеп зур эшләр башкарырга кирәк. Бу юнәлештә Самара татар милли хәрәкәт юлбашчылары көчәнә-көчәнә алга баралар.

Без бу кыенлыкларны, югалтуларны Ходай Тәгаләләрафыннан бирелгән сынаулар итеп карарга тиешбез. Сиксән ел саташулардан соң, ватаныбыз Русия гаҗәеп авырлык белән шәхеснең рухи пәрдәсен имгәкләтүен аңлый башлады кебек. Җәмгыятьтә, чамалы булса да шартлы иреклек бар. Хәзер күп нәрсә кешенең үзеннән тора, шул ук вакытта шәхес милли йөрәкле әйдаманнарга мохтаҗ. Самарада шундыйларның берсе - Гомәр Мулланур углы Батыршин.

Гомәр әфәнде Батыршин берничә ел элек Самарада "Болгар мирасы" исемле фонд оештырып җибәрде. Миллионлы Самараның Зубчаниновка бистәсендә мәчет салдырды. Болгар дәүләтенең көньяк чигенә туры килгән, болгарлар заманында таможня ноктасы булып хезмәт иткән җирдә стелла куйдырды. Биеклеге - алты метр ярым. Һәйкәлнең башында - горур барс.

Гомәр Батыршин "Булгарская цивилизация на Волге" исемле китапны да үз акчасына бастырды. Төпле китап. Татарның атаклы тарих галимнәре,тарих фәннәре докторлары, профессорлар Гамирҗан Дәүләтшин һәм Фаяз Хуҗин китапның беренче өлешен язганнар. Китапның авторы - Фәрид Шириязданов дистәләгән тарихи чыганакларны эшкәртеп, гаҗәеп бай эчтәлекле болгар чорына кагылган тарихи мәгълүматлар туплый алган. Шуны да искәртеп узарга кирәктер, гади укучыга тарихи дәреслекне Фәрид Шириязданов "чәйнәп" биргән. Гади тел, аңлаешлы җөмләләр.

Китапның кирәклегенә бик күп сәбәпләр бар. Бүгенге көндә татар гаиләсендә милләтебезгә, телебезгә, динебез Исламга хөрмәт тәрбияләнми. Үз милләте белән горурланып яшәүчеләр бармак белән санарлык. Иң аянычы шунда ки, татарлыктан гарьләнүчеләр арта бара.

Рус китапларында мәктәп баласына татарны вәхши образында китереп куялар. Татарны тамырсыз килмешәк итеп күрсәтәләр. Сабый күңеленә үз татарына каршы агу салалар.

Мин Гомәр Батыршинга берничә сорау бирдем:

- **Ни өчен Идел болгарлары турында китап яздырырга булдың?**

- Самарада яшәгән татарларга да: "Сез - Монголиядән килгәннәр", - дип әйтүчеләр бар.Татарның көчле дәүләткә ия булып яшәгәнен белмиләр һәм иң аянычы: белергә дә теләмәүчеләр бар. Татар - империяләр тоткан халык. Ул сәүдә юлларын ачып кына калмаган, ул шул юлларны саклауны да оештырган. Татарның чәчәк аткан дәүләте - ул Болгар дәүләте. Быолгар дәүләтеннән үрнәк алучылар исемлеген санап тормыйча, шуны әйтү дә җитәр, дип саныйм. Рус дәүләте күп нәрсәне татардан күчергән. Тикмәгә генә Болгар дәүләтен руслар "Светоч Востока", "Золотой трон Востока," "Царство разума" димәгәннәр бит инде. Бүгенге көндә төрле милләтләрне үзара тату яшәтергә өндиләр. Болгар җирлегендә төрле кавемнәр дустанә көн күргәннәр.

- **Китапның авторы - "Ислам-Нур" гәҗитәсенең мөхәррире Фәрид Шириязданов. Сез аның хезмәте белән канәгатьме?**

- Һичшиксез. Галимнәрнең авыр телен гади укучы аңларлык итте. Китапның икенче бүлеге тулысынча Фәрид Шириязданов хезмәте. Фәрид абый интеллектуал. Тарихны тирән белә. Рус һәм татар телләрендә камил фикер йөртә һәм аны хатасыз кәгазьгә төшерә белүче талант. Дистәләгән тарихи чыганакларны укып чыгып, аларны иләп, сөзеп, сокланырлык хронология ясады.




- **Китапта Сез куйган максат ирешелгәнме?**

- Бер китапка бар тарихны сыйдырып булмый. Китапны күпләр укыды, укый һәм аларның фикере бер: "Булгарская цивилизация на Волге" җыентыгы татар кешесендә горурлык уята, башка милләт вәкиленең күзен ача.

Самараның татар эшбатырлары да, гади халык та җыентыкны кызыксынып укыйлар. Менә кайбер фикерләр.

Рифкать Хуҗин: «Йотлыгып укыдым. Татарлыкны арттыра торган китап.»

Миннәхмәт Хәлиуллов: «Беренчедән, китап зәвык белән эшләнгән. Кулга аласы килә һәм укыйсы килә. Болгар дәүләтенә кагылган хронологияне бер җирдә туплап бирү - китапның отышлы ягы. Акыл өстәүче чыганак».

Равил Галимов: «Үзем генә укып калмадым, әле дистәләгән кешегә бүләк итеп тә бирдем. Татарны канатландыручы китап».

Наилә Сабирҗанова: «Гаиләбез белән укыдык. Уртак фикеребез: яхшы язылган. Дәлилле язылган.Татарның күзен ача торган җыентык. Мөхәррир буларак, Фәрид Шириязданов зур көч куйган. Фәнни җыентык булуга карамастан, талчыкмый укыйсың. Күңелне рәнҗетерлек нәрсәләр юк. Уку дәверендә рәхәтлек тойгысы китми».

Мең данә белән басылган китап инде таралып та бетте. Гомәр Батыршин өстәмә тираж турында уйлана.

**Шамил БАҺАУТДИН.**
**Әнәс МИНГАЛИЕВ**
**фотосурәтләре.**



Миннәхмәт Хәлиуллов Гомәр Батыршинга Самара өлкәсенең татар милли-мәдәни мохтарияте исеменнән Рәхмәт хаты тапшыра

Риваять

# Сөекле шәкерт

Багдадта яшәүче шейх Җүнәид хәзрәтнең бик тырыш егерме шәкерте бар иде. Хәзрәт бөтен шәкертләрен бик хөрмәт итә торган булса да, араларыннан берсен - Габдулланы артыграк сөя һәм ихтирам итә иде. Көннәрнең бер көнендә, дәрес беткәннән соң, унтугыз шәкерт бергә җыелып, Җүнәид хәзрәт янына килделәр һәм әйттеләр:

- Хөрмәтле хәзрәтебез, без бер әйберне аңлый һәм тыныч кына кабул итә алмыйбыз. Нигә син Габдулланы барыбыздан да артыграк сөясең һәм аңа күбрәк хөрмәт күрсәтәсең? Ул да синең шәкертең, без дә синең шәкертләрең. Ул да яхшы укый, без дә бер дә артта калмыйбыз. Бәлки, арабыздан аннан да яхшырак укучыларыбыз бар?

Җүнәид хәзрәт аларның сорауларына:

- Әй, шәкертләрем, сабыр булыгыз, әлеге сорауга җавапны тиздән үзегез үк күреп, ишетә алырсыз, - дип җавап бирде.

Әлбәттә, хәзрәтнең бу сүзләре шәкертләрне канәгатьләндермәде. Алар һәммәсе дә, таралышып, өйләренә кайтып киттеләр.

Шулай берничә атна үтеп тә китте. Шәкертләрнең күбесе хәзрәтләренә биргән сорауларын да оныткан иде. Бер көнне, дәрес беткәннән соң, хәзрәт шәкертләренә шундый сүзләр белән эндәште:

- Әй, хөрмәтле, нурлы йөзле шәкертләрем! Иртәгәгә сезгә бер өй эше бирәм. Бүген барыгыз да өегезгә кайтып киткән вакытыгызда мәдрәсә сараеннан берәр тавык алыгыз, аннан тавыкларны сезне беркем дә күрмәгән җирдә суеп, чистартып китерегез.

Шәкертләр бик сөенеп, җиңел булып күренгән һәм кызык кебек тоелган өй эшен алып кайтып киттеләр.

Икенче көнне иртәнге дәрескә шәкертләр өй эшләрен әзерләп килгәннәр: тавыклары суелган, чистартылган иде. Араларыннан берсе - Габдулланың гына тавыгы кулында кыткылдап тора иде. Шәкертләр һәммәсе дә аңа карап сәерсенделәр: «Ничек инде хәзрәтебез кушканны эшләп килмәгән?» - дип уйлап торганда Җүнәид хәзрәт аңардан:

- Әй, Габдулла, нигә син өй эшен эшләмәдең? Сине беркем дә күрмәгән җирдә тавыкны суеп, чистартып килмәдең? - дип сорап куйгач, ул:

- Гафу ит, сөекле остазым, мин Аллаһы Тәгалә күрмәгән җир таба алмадым, - дип җавап кайтарды. Бу җавапны ишеткән Җүнәид хәзрәт шатланып елмайды һәм Габдулланы кочаклап алды да: «Ни өчен Габдулланы безгә караганда күбрәк сөясең?» - дип әйткән шәкертләренә:

- Әй, шәкертләрем, инде белдегезме, ни өчен мин аны артыграк сөйгәнемне? Ул Коръән хәдисләре генә ятлап чикләнми, гыйлемен күтәрүе белән бергә ихласлылыгын һәм Аллаһыга мәхәббәтен дә арттыра. Чын шәкерт, чын Аллаһы бәндәсе белеме һәм гамәле белән бергә ихласлылыгын да арттырырга тиеш, - дип әйтте.

Хөрмәтле дустым, бел шуны: иман ныгысын өчен гыйлем алып, гамәл кылу гына җитми. Иман камилләшсен өчен тагын бер нәрсә кирәк: ул да булса - ихласлылык. Иман - ул бер агач кебек, аның тамырлары - гыйлем алу, агъни белмәгәнеңне өйрәнү, ботаклары - гамәл кылу, агъни белгәнеңне эшләү, ә җимешләре - ихласлылык. Әгәр дә агачның тамырлары, ботаклары булып та, җимешләре булмаса, аның файдасы да бик аз була. Гыйлем һәм гамәлнең җимеше булган ихласлылык нәрсә соң ул? Җәбраил (г.с.) кеше сурәтендә Пәйгамбәребез Мөхәммәт (г.с.) янына килеп, бу сорауны аңа бирде һәм Пәйгамбәребез шушындый җавап кайтарды:

*«Ихласлылык башка төрле әйткәндә - ихсан. Аллаһы Тәгаләне күрмәсәң дә, күргән кебек гыйбадәт итүең. Син бит аны күрә алмасаң да, Ул сине, һичшиксез, күреп тора» , - дип гамәл итү».*

Әй, сөекле дустым! Җүнәид хәзрәтнең шәкерте Габдулла кебек була күр. Кая гына булсаң да, нәрсә генә эшләсәң дә, нинди генә хәлдә булсаң да, сине күреп торучы, һәр хәрәкәтеңне күзәтеп торучы Аллаһы Тәгаләне күңелеңнән чыгара күрмә.

***Әлмира ӘДИЯТУЛЛИНА.***